| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 15.11.2024 | г.Казань | № 328-34/кс-2024 |

«Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2023 ел, №377-26/кс-2023 карары белән техник суга билгеләнгән озак сроклы тарифларны 2025 елга төзәтү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2023 ел, №377-26/кс-2023 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 15.11.2024 ел, №26-ПР беркетмәсе нигезендә, 2025 елга техник суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулаем кеременә төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен 2024-2028 елларга техник суга тарифлар билгеләү турында» 15.11.2023 ел, №377-26/кс-2023 карары белән «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга билгеләнгән тарифларны 2025 елга үзгәртеп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).
2. Әлеге карарның 1 пункты белән төзәтелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024-2028 елларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга тарифлар билгеләү турында» 15.11.2023 ел, №377-26/кс-2023 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024-2028 елларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуы турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.1-3.2 пунктлар өстәргә:

"3.1. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә «Татэнерго» АҖ су белән тәэмин итү өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

3.2. Әлеге карарның 3.1 пункты белән расланган җитештерү программасы 2025 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.»;

3 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2023 ел, №377-26/кс-2023
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2024 № 328-34/кс-2024
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүче «Татэнерго» АҖ өчен 2024 – 2028 елларга техник суга тарифлар

| №т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ, «Казан җылылык электр үзәге-1» филиалы (тарифлар өстәлгән хак бәясен исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 5,67 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 6,49 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 6,22 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 6,22 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 6,19 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 6,48 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 6,48 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 6,48 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 6,48 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 6,79 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2023 ел, №377-26/кс-2023
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2024 № 328-34/кс-2024
карары редакциясендә)

**Оешманың җитештерү программасы**

**1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Җайга салынулы оешма** | «Татэнерго» АЖ, «Казан җылылык электр үзәге-1» филиалы | | | |
| Урнашкан урыны | 420021 ел. Казан, Марсель Сәлимҗанов ур., 1 й. | | | |
| **Җайга салуның вәкаләтле органы** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2025 | тәмамлана | 31.12.2028 |

**2 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм су агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларын ремонтлау чаралары, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметү чаралары исемлеге**

| № | Аталышы | Үлчәү берәмлеге | Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** |
| 1ХВС – Техник суга тариф – су белән тәэмин итү | | | | | | |
| 1 | Агымдагы ремонт | мең сум | 9 976,81 | 10 301,76 | 10 606,69 | 10 920,65 |
| 2 | Капиталь ремонт | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3 | Башка чаралар, шул исәптән энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чараларына юнәлдерелгән чаралар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

**3 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән су**

1ХВС – Техник суга тариф – су белән тәэмин итү

| № | Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** |
| 1 | Күтәрелгән су күләме | мең м3 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 |
| 2 | Технологик ихтыяҗларга су күләме | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3 | Читтән алынган су күләме | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 4 | Чистарту корылмалары аша үткәрелгән су күләме | мең м3 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 |
| 5 | Челтәргә бирелгән су | мең м3 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Су югалту күләме | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 7 | Су җибәрелгән, барлыгы | мең м3 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 | 6 182,16 |
| 8 | Предприятие ихтыяҗларына тотыла торган су күләме | мең м3 | 2 708,36 | 2 708,36 | 2 708,36 | 2 708,36 |
| 9 | Кулланучыларга су җибәрү (сату), барлыгы, шул исәптән: | мең м3 | 3 473,80 | 3 473,80 | 3 473,80 | 3 473,80 |
| 9.1 | су белән тәэмин итүнең башка оешмаларына | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 9.2 | халыкка | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 9.3 | бюджет оешмаларына | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 9.4 | башка кулланучыларга | мең м3 | 3 473,80 | 3 473,80 | 3 473,80 | 3 473,80 |

**4 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** |
| 1 | Җитештерү чыгымнары | мең сум | 18 655,07 | 19 262,66 | 19 832,84 | 20 419,89 |
| 1.1 | Хезмәт өчен түләү һәм социаль ихтыяҗларга түләү чыгымнары | мең сум | 10 740,90 | 11 090,73 | 11 419,02 | 11 757,02 |
| 2 | Ремонт чыгымнары | мең сум | 9 976,81 | 10 301,76 | 10 606,69 | 10 920,65 |
| 3 | Административ чыгымнар | мең сум | 197,39 | 203,82 | 209,85 | 216,06 |
| 4 | Сату чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5 | Амортизация | мең сум | 650,51 | 650,51 | 650,51 | 650,51 |
| 6 | Аренда һәм концессия түләүләре, лизинг түләүләре | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 7 | Салымнар һәм җыемнар | мең сум | 8 990,23 | 8 990,23 | 8 990,23 | 8 990,23 |
| 8 | Норматив табыш | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 8.1 | Капиталь чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 9 | Гарантияләүче оешманың исәпләмә эшкуарлык табышы | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10 | Узган чорларның алынмаган керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10.1 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10.2 | Җайга салуның узган чорларында алынмаган керемнәр | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10.3 | Акча җитмәүне каплауга юнәлдерелгән заем акчаларына һәм үз акчаларына хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 11 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый яктан нигезләнмәгән керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 | 2 297,42 | 2 297,42 | 2 297,42 |
| 12 | Кирәкле тулай табыш | мең сум | 38 470,01 | 37 111,56 | 37 992,70 | 38 899,92 |

**5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы**

| № | Чараның аталышы | план чоры |
|---|---|---|
| 1 | Су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау. | 2025-2028 |

<table>
<tr><th colspan="7">6 нчы бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы күрсәткечләре</th></tr>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2">Күрсәткеч</th><th rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</th><th colspan="4">Күрсәткеч зурлыгы</th></tr>
<tr><th>2025</th><th>2026</th><th>2027</th><th>2028</th></tr>
<tr><td colspan="7">1ХВС – Техник суга тариф – су белән тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="6">Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзлексезлеге күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td>1.1</td><td>Пн – Салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларындагы аварияләр, зарарланулар һәм башка технологик хокук бозулар нәтиҗәсендә салкын су белән тәэмин итү буенча салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың йөкләмәләрен үтәү урыннарында салкын су белән тәэмин итү шартнамәсендә, бердәй су белән тәэмин итү һәм су түгү шартнамәсендә яисә салкын су ташу шартнамәсендә билгеләнгән өзеклекләр саны салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың су белән тәэмин итүләре, елга сүүткәргеч челтәренең озынлыгын исәпләп, бер елга</td><td>бер./км</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="6">Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td>2.1</td><td>Дпв – сүүткәргеч челтәренә бирелгән суның гомуми күләмендә суны транспортировкалаганда үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларында су югалтулар өлеше</td><td>%</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2.2</td><td>Урп – Техник су әзерләүнең технологик процессында кулланыла торган электр энергиясе челтәргә җибәрелә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы</td><td>кВт*сәг/куб.м</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">-</td></tr>
<tr><td>2.3</td><td>Урп – Техник суны транспортлауның технологик процессында кулланыла торган электр энергиясенең транспортлана торган техник су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы</td><td>кВт*сәг/куб.м</td></tr>
<tr><th colspan="7">7 нче бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының аның гамәлдә булу чоры дәвамында үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү</th></tr>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2">Күрсәткеч</th><th rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</th><th colspan="4">Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы</th></tr>
<tr><th>2025</th><th>2026</th><th>2027</th><th>2028</th></tr>
<tr><td colspan="7">1ХВС – Техник суга тариф – су белән тәэмин итү</td></tr>
<tr><td></td><td>Үзгәреш динамикасын чагыштыру</td><td>%</td><td colspan="4">Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә.</td></tr>
<tr><th colspan="7">8 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап</th></tr>
<tr><td colspan="7">Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2023 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән.</td></tr>
<tr><th colspan="7">9 нчы бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар</th></tr>
<tr><td>№</td><td colspan="6">Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган.</td></tr>
</table>